**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12418**
**22.12.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 24 мартындагы 2087 номерлы, 2023 елның 7 июлендәге 5940 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 35, 36 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «35. | Гомуми белем бирү оешмаларында хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел саен | гомуми белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализациясе төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 57 603,07 | 57 643,00 | 57 643,00 |
| 36. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел саен | мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализациясе төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 84 915,12 | 84 875,18 | 84 875,18»; |

2) 8 бүлекнең 39, 40 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «39. | Мәдәният учреждениеләрендә хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | ел саен | мәдәният учреждениеләренең төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализация се төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 9 266,42 | 9 035,70 | 9 035,70 |
| 40. | Физик культура һәм спорт учреждениеләрендә хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | физик культура һәм спорт учреждениеләренең төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализация се төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 13 306,37 | 13 537,10 | 13 537,10». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов